**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

«9» декабря 2024 ел **№ 156**

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 6 октябрендәге 257 номерлы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2024 елның 18 октябрендәге 1-31/15348 номерлы хатын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 6 октябрендәге 257 номерлы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» карарына (26.08.2022 № 164, 14.11.2022 № 249, 06.03.2024 № 33, 02.10.2024 № 122 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

А) күрсәтелгән карарның 1.3 пункты белән расланган Муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына:

1) 3.3.3.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.3.4. Регламентның 3.3.3.1, 3.3.3.3 пунктларында күрсәтелгән процедуралар, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда башкарыла.

Регламентның 3.3.3.1, 3.3.3.3 пунктларында күрсәтелгән һәм шул исәптән пространстволы күрсәткечләрдән файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында пространстволы мәгълүматларның милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын куллану рөхсәт ителә.»;

2) 3.4.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.5. Регламентның 3.4.2, 3.4.4, 3.4.5 пунктларында күрсәтелгән процедуралар, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан

файдаланып, автомат режимда, шул исәптән Регламентның 2.13 пункты нигезендә гаризаны теркәү вакытыннан башлап гамәлгә ашырыла.

Регламентның 3.4.2, 3.4.4, 3.4.5 пунктларында күрсәтелгән һәм пространство күрсәткечләреннән файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында пространстволы мәгълүматларның милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын куллану рөхсәт ителә.»;

3) 3.5.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.4. Регламентның 3.5.2, 3.5.3 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда гамәлгә ашырыла.

Регламентның 3.5.2-3.5.3.3 пунктларында күрсәтелгән аерым процедураларны башкару кысаларында, шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле булган федераль дәүләт Географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә, ул пространство белешмәләренең милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә.»;

4) түбәндәге эчтәлекле 3.5.5 пункт өстәргә:

«3.5.5. Регламентның 3.5 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны башкаруның максималь вакыты 14 эш көнен тәшкил итә.»;

5) 3.6.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.1. Административ процедураны үти башлау өчен нигез булып административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазифаи зат тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне раслый торган документны алу тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат - палата рәисе урынбасары (алга таба - документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазыйфаи зат).

Документларны бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазифаи зат:

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасы документациясен алып бару подсистемасына, шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итү буенча дәүләт мәгълүмат системасына муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында мәгълүматларны теркәүне һәм кертүне тәэмин итә;

- гариза бирүчегә (аның вәкиленә) Республика порталы аша электрон хезмәттәшлек ярдәмендә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен күпфункцияле үзәктә алу мөмкинлеге турында хәбәр итә.

Процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда гамәлгә ашырыла.

Пространство мәгълүматларыннан файдалануга бәйле процедураларны үтәү кысаларында пространство мәгълүматларының милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын куллану рөхсәт ителә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән административ процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтүне (бирүдән баш тартуны) раслаучы документны

имзалаган көннән алып бер эш көне эчендә Палатаның (Палата) вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан башкарыла.

Административ процедуралар башкарылу нәтиҗәсе: муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында белешмәләрне мәгълүмат системаларына урнаштыру, мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе һәм аны алу ысуллары турында хәбәр итү.»;

Б) күрсәтелгән карарның 1.4 пункты белән расланган, Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген, сатулар үткәрмичә, милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, бушлай файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына:

1) 3.3.3.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.3.4. Регламентның 3.3.1, 3.3.3 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автоматик режимда гамәлгә ашырыла.

Регламентның 3.3.3.1, 3.3.3.3 пунктларында күрсәтелгән һәм шул исәптән пространстволы күрсәткечләрдән файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында пространстволы мәгълүматларның милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын куллану рөхсәт ителә.»;

2) 3.4.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.5. Регламентның 3.4.2, 3.4.4, 3.4.5 пунктларында күрсәтелгән процедуралар, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан файдаланып, автомат режимда, шул исәптән Регламентның 2.13 пункты нигезендә гаризаны теркәү вакытыннан башлап гамәлгә ашырыла.

Регламентның 3.4.2, 3.4.4, 3.4.5 пунктларында күрсәтелгән һәм пространство күрсәткечләреннән файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында пространстволы мәгълүматларның милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын куллану рөхсәт ителә.»;

3) 3.5.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.6. Регламентның 3.5.3-3.5.5 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автоматлаштырылган режимда гамәлгә ашырыла.

Регламентның 3.5.3-3.5.5 пунктларында күрсәтелгән аерым процедураларны башкару кысаларында, шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле булган федераль дәүләт Географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә, ул пространство белешмәләренең милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә.»;

4) түбәндәге эчтәлекле 3.5.7 пункт белән тулыландырырга:

«3.5.7. Регламентның 3.5 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны үтәүнең максималь срогы: 14 эш көнен тәшкил итә, биреләсе җир кишәрлеге турында хәбәр басылып чыккан очракта - 47 эш көне.»;

5) 3.6.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.2. Документларны бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазифаи зат:

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасының документлар белән эшләү буенча ярдәмче системасында һәм (яки) шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында мәгълүматларны теркәүне һәм кертүне тәэмин итә;

- мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) гаризада күрсәтелгән ысул белән Палатада яки КФҮтә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алу мөмкинлеге турында хәбәр итә.

Процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда гамәлгә ашырыла.

Пространство мәгълүматларыннан файдалануга бәйле процедураларны үтәү кысаларында пространство мәгълүматларының милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын куллану рөхсәт ителә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән административ процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтүне (бирүдән баш тартуны) раслаучы документны имзалаган көннән алып бер эш көне эчендә Палатаның (Палата) вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан башкарыла.

Административ процедуралар башкарылу нәтиҗәсе: муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында белешмәләрне мәгълүмат системаларына урнаштыру, мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе һәм аны алу ысуллары турында хәбәр итү.».

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин